## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод авылы торак
пунктында 2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 23 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Петровский Завод авыл җирлеге территориясендә I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Петровкий Завод авылын төзекләндерү эшләренә түләү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, аларның эшләренә түләү);
- Петровский Завод авылында мәдәни чаралар уздыру өчен бүләкләр алу (Сабантуй, өлкәннәр көне, инвалидлар коне, 9 Май):
- Петровский Завод авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;
- Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүченең эш хакы, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Петровский Завод авылы зиратына юл салу һәм аларның эшләренә түләү;
- Петровский Завод авылынын Узэк урамынын бер олешенэ юл салу һәм аларның эшләренә түләү;
- Петровский Завод авылынын Совет урамынын керэ торган олешенэ юл салу һәм аларның эшләренә түләү;
- Петровский Завод авылынын Завод урамынын бер олешенэ юл салу һәм аларның эшләренә түләү;
- бензин чүкеч, бензобур, бензодрели, бензин кар чистартучы сатып алу;
- Петровский Завод авылында агач кисү;

- Петровский Завод авылынын зират коймасын алыштыру очен материаллар алу;
- Петровский Завод авылынын рус зираты очен чуп савыты алу;
- Петровский Завод авылында су башнясы территориясен тоту хэм насос будкасы тозу очен материаллар алу;
- трактор очен асылмалы жихазлар алу очен;
- Петровский Завод авылында урнашкан балалар мэйданчыкларын тозеклэндеру очен материаллар алу;

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А.Б. Хөснетдинов